# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлегенең Каташ-Каран авылы торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

**26 ноябрь 2024 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 26 ноябрендә 10.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2025 елда 350 сум үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан, шул исәптән катнашучы контрактчылардан (махсус хәрби операция барышында) һәм аларның гаилә әгъзаларенән тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1) Каташ-Каран зиратында куаклар һәм агачлар кисү;

2) Каташ Каран авылындагы юлларны кардан чистарту (спецтехника арендалау, килешү буенча эш өчен түләү).

3) Каташ-Каран торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (светодиодлы лампаларны сатып алу һәм урнаштыру);

4) Каташ-Каран торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү, төзелеш материаллары сатып алу, төзелеш эшләре (килешү буенча эш өчен түләү), куаклар һәм агачлар кисү.

5) Каташ-Каран авылына керү,чыгу юлларына видеокамера җиһазлары алу, урнаштыру.

6) Каташ-Каран урамына юл билгеләре сатып алу, урнаштыру.

7) Каташ-Каран авылында су башнясына баручы юлга таш җәю,тигезләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 239 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 159 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 159 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен ___0_____ катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Янурыс авыл жирлегенең Каташ-Карана вылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2025 елда 350 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан, шул исәптән катнашучы контрактчылардан (махсус хәрби операция барышында) һәм аларның гаилә әгъзаларенән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Каташ-Каран зиратында куаклар һәм агачлар кисү;

2) Каташ Каран авылындагы юлларны кардан чистарту (спецтехника арендалау, килешү буенча эш өчен түләү).

3) Каташ-Каран торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (светодиодлы лампаларны сатып алу һәм урнаштыру);

4) Каташ-Каран торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү, төзелеш материаллары сатып алу, төзелеш эшләре (килешү буенча эш өчен түләү), куаклар һәм агачлар кисү.

5) Каташ-Каран авылына керү,чыгу юлларына видеокамера җиһазлары алу, урнаштыру.

6) Каташ-Каран урамына юл билгеләре сатып алу, урнаштыру.

7) Каташ-Каран авылында су башнясына баручы юлга таш җәю,тигезләү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Янурыс авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче А. Ә.Мөхәммәдиева